# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Бишнә авыл җирлегенең Кызыл Кармыш авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

2024 елның 26 марты №5

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2024 елның 26 мартында 16 сәгать 00 минутта узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: «Сез Зеленодольск муниципаль районы Бишнә авыл җирлегенең Кызыл Кармыш авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы 2023 елның 19 ноябрендәге 7 номерлы «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Бишнә авыл җирлегенең Кызыл Кармыш авылында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында»гы карарына һәм 2023 елның 19 ноябрендәге 8 номерлы «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Бишнә авыл җирлегенең Кызыл Кармыш авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында»гы» карарларга җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча эшләр исемлеге өлешендә үзгәрешләр кертүгә ризамы:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (инерт материаллар сатып алу, шул исәптән объектларны техник паспортлаштыру, смета документларын әзерләү, төзелеш контролен гамәлгә ашыру);
- каты коммуналь калдыклар туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыклар җыю өчен контейнерлар сатып алу, санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү (шул исәптән смета документларын әзерләү, төзелеш контролен гамәлгә ашыру);
- карардагы «500 сум» сүзләрен «2000 сум» сүзләренә алыштырырга:

«Әйе» "КАРШЫ".

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 29 гражданнар җыенында катнашучы кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 18 кеше, бу 62% тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленгән:

«за» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 17 кеше тавыш бирә; «каршы» позициясе өчен җыенда катнашучы 1 кеше тавыш бирә.

Шушы нигездә, гражданнар җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Бишнә авыл җирлегенең Кызыл Кармыш авылы торак пунктында гражданнар җыены узган дип танырга, гражданнар җыены нәтиҗәләре гамәлдә дип танырга.

2. Гражданнар җыенына чыгарылган мәсьәлә буенча карар кабул ителгән дип танырга.

3. 2024 елда Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Бишнә авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәм даими яшәүче һәр балигъ булган кешедән, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан һәм мобилизацияләнгән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 2000 сум күләмендә үзара салым кертү чараларын кертергә.

4. 2024 елда алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (инерт материаллар сатып алу, шул исәптән объектларны техник паспортлаштыру, смета документларын әзерләү, төзелеш контролен гамәлгә ашыру);
- каты коммуналь калдыклар туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыклар җыю өчен контейнерлар сатып алу, санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү (шул исәптән смета документларын әзерләү, төзелеш контролен гамәлгә ашыру).

5. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында, (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) Интернет челтәрендә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче И.М.Фатхуллин